ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№__203__

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«_16_» __ноябрь__20_20_ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы указлары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелүче Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 15 августындагы 309 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2020 елның «16» ноябрендәге 203 номерлы боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕ ВАКАНТ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТЕЛҮГӘ) КОНКУРС УЗДЫРУ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) эшләү чорлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә (алга таба – ТР ДТИ) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә карата тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуы буенча конституциячел хокукларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. ТР ДТИ конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы (алга таба – Федераль закон), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы, Татарстан Республикасы Президентының

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы указлары нигезендә үткәрелә.

Конкурс дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең профессиональ дәрәҗәсен, аларның граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс Федераль закон нигезендә конкурс нигезендә биләнергә мөмкин булган граждан хезмәте вакант вазыйфасы булганда ТР ДТИ җитәкчесенең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) (алга таба – җитәкче) карары белән игълан ителә.

1.4. ТР ДТИ кадрлар резервына кертелүгә конкурс кадрлар бүлеге тарафыннан, ТР ДТИнең дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфаларын биләүдә белгечләргә ихтимал ихтыяҗын һәм ТР ДТИдә булган кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

ТР ДТИ кадрлар резервына кертелүгә конкурс ТР ДТИ конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Федераль законның 57 статьясының 1 өлешендәге 2 яисә 3 пунктында яки 59.1 статьясының 2 яисә 3 пунктында каралган дисциплинар йөкләмәсе булган граждан хезмәткәре ТР ДТИ кадрлар резервына кертелә алмый.

1.6. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен ТР ДТИ кадрлар резервын формалаштыру.

1.7. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

объектив һөнәри әһәмиятле критерияләр нигезендә кандидатларны бәяләү;

конкурста катнашучылар арасыннан, конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалары (кадрлар резервына кертү) таләпләренә җавап бирә торган затларны ачыклау.

1.8. ТР ДТИ граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

«җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен билгеле бер чорга биләү өчен билгеләнгәндә;

вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.9. ТР ДТИ граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, ТР ДТИ боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

ТР ДТИ җитәкчесе карары буенча, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнгәндә.

1.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

1.11. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язмача гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелә. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар ТР ДТИ архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

1.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак бинага түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан түләнә.

## II. КОНКУРС КОМИССИЯСЕ ТӨЗҮ ҺӘМ АНЫҢ ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

2.1. ТР ДТИ конкурслар уздыру өчен ТР ДТИ җитәкчесе боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе составы ТР ДТИ җитәкчесе боерыгы белән раслана.

Конкурс комиссиясенең объективлылыгын һәм эшенең бәйсезлеген арттыру максатларында ТР ДТИ җитәкчесе карары нигезендә аның составы даими рәвештә (ел саен) үзгәреп тора.

Конкурсларны нәтиҗәле оештыру максатларында ТР ДТИ җитәкчесе карары буенча дәүләт органында граждан хезмәте вазыйфаларының төрле категорияләре һәм төркемнәре өчен берничә конкурс комиссияләрен оештыру рөхсәт ителә.

2.2. Конкурс комиссиясе Рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясенең сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итү, эшләрне формалаштыру, конкурс комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. ТР ДТИ конкурс комиссиясе составына ТР ДТИ җитәкчесенең беренче урынбасары, ТР ДТИ җитәкчесе урынбасарлары һәм (яки) җитәкче тарафыннан вәкаләт бирелгән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән ТР ДТИнең кадрлар, хокук идарәсе бүлегеннән һәм ТР ДТИнең граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәсеннән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук ТР ДТИ рәсми мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр сыйфатында экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, белем бирү һәм башка оешмаларның вәкилләре керә. Бәйсез экспертларның саны конкурс комиссиясендәге әгъзаларның гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

ТР ДТИ каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

2.5. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырылганда конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми исәбендәге кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Кандидат белән конкурс комиссиясе тарафыннан кара-каршы шәхси әңгәмә уздырмыйча конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карарын кабул итү рөхсәт ителми.

Утырышны видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булган очракта) уздыру турында конкурс комиссиясе карары аның әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме белән мондый карар сәбәбен (нигезен) күрсәтеп кабул ителә.

2.9. Конкурс комиссиясенең карары кандидат юклыгында кабул ителә.

2.10. Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе утырышына рәислек итүче затның тавышы хәл иткеч була.

2.11. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына туры китерелгән формада конкурс комиссиясе

карары белән рәсмиләштерелә. Кадрлар резервына керү буенча конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасына туры китерелгән формада конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Аталган карарда һәм беркетмәдә, туплаган балларын һәм конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча алар тарафыннан яуланган урыннарны күрсәтеп, кандидатлар рейтингы була.

2.12. Конкурс үткәрүне һәм конкурс үткәрүне, конкурс комиссиясе эшен тәэмин итүне турыдан-туры ТР ДТИ кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. ТР ДТИ граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча кандидатларга карата таләпләргә җавап бирә торган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган чорда әлеге Нигезләмәнең 3.4 яки 3.5 пунктларында күрсәтелгән документларны тиешенчә тапшырган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – гражданнар), шулай ук граждан хезмәткәрләре конкурста катнашуга кертелә.

3.2. Граждан хезмәте вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләренә бәйле рәвештә гражданин (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми.

3.3. ТР ДТИ граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) өчен кандидатларга карата таләпләр дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнде.

3.4. Конкурста катнашырга теләк белдергән гражданин ТР ДТИ түбәндәгеләрне тапшыра:

шәхси гариза (әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасына туры китерелгән формада);

Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формада тутырылган һәм имзаланган анкета, фото белән;

паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданинның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);

белеме турында һәм квалификациясе турында документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификациясен күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе;

гражданинда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәпкә алу формасы);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

3.5. Конкурста катнашу теләген белдергән, ТР ДТИ граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре гаризаны ТР ДТИ җитәкчесе исеменә тапшыра.

Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре ТР ДТИ җитәкчесе исеменә шәхси гариза һәм үзе тарафыннан тутырылган, имзаланган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәтераслаган рәвештәге анкетаны фотосын теркәп ТР ДТИ тапшыра.

3.6. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан биләү өчен дәгъва белдерелгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Граждан тарафыннан ТР ДТИ җитәкчесе исеменә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турында «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең ярдәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында (алга таба – Федераль мәгълүмат системасы) игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көне эчендә ТР ДТИ гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәреп яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

Хөрмәткә лаек сәбәпсез документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда ТР ДТИ җитәкчесе аларны карап тикшерүнең вакытын күчерергә хокуклы.

## IV. Конкурсны уздыру методикасы

4.1. Конкурсларны уздыруга әзерлек кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын (алга таба – бәяләү методлары) сайлауны һәм аларга туры килә торган конкурс биремнәрен формалаштыруны, зарурлык булганда граждан хезмәтенең аларны биләү буенча конкурс игълан итү планлаштырыла торган

вакантлы вазыйфаларына карата граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары нигезләмәләрен актуальләштерүне күздә тота.

4.2. Граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларының нигезләмәләрен актуальләштерү, бәяләү методларын сайлау һәм аларга туры килә торган конкурс биремнәрен формалаштыру ТР ДТИ мәнфәгатьле бүлекчәсе тарафыннан кадрлар бүлеге белән килештереп гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләү методларын куллану һәм конкурс биремнәрен формалаштыру турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

ТР ДТИ җитәкчесе карары нигезендә граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына карата конкрет белгечлеккә (әзерлек юнәлешенә) карата квалификация таләпләре куелырга мөмкин.

4.3. Кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, аларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү өчен конкурс процедуралары барышында федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларына каршы килми торган бәяләү методлары кулланылырга мөмкин.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.5. Беренче этапта ТР ДТИ кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс уздыру турында мәгълүматны әзерли һәм ТР ДТИ һәм Федераль мәгълүмат системасы рәсми сайтларында урнаштыра, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы, әлеге вазыйфаны биләү өчен кандидатка белдерелә торган квалификация таләпләре, граждан хезмәтен узу шартлары, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны ТР ДТИ кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итү срогы, конкурсны уздыруның күздә тотылган датасы, аны уздыру урыны һәм тәртибе, бәяләү методлары турында белешмәләр, граждан хезмәткәренең вазыйфа бурычларын, хокукларын һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыгын үз эченә алган вазыйфаи регламенты нигезләмәләре, граждан хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлегенең файдалылык һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, Федераль мәгълүмат системасында урнаштырылган беренчел квалификация тестына сылтама, башка мәгълүмат материаллары;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерүне:

гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

4.6. Кандидат конкурстан читтә үзенең профессиональ дәрәҗәсен мөстәкыйль бәяләү өчен беренчел квалификация тестын узарга мөмкин, бу хакта конкурс игъланында күрсәтелә.

Беренчел тестта кандидатларның Росия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү дәрәҗәсен, Россия Федерациясе Конституциясе нигезләре, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары

турындагы белемнәрен, мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендәге белемнәрен һәм күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр була.

Беренчел тест Федераль мәгълүмат системасы рәсми сайтында урнаштырыла, аны узу мөмкинлеге кандидатлар өчен түләүсез нигездә бирелә.

Кандидат тарафыннан беренчел тестны узу нәтиҗәләре конкурс комиссиясе тарафыннан игътибарга алына алмый һәм конкурста катнашу өчен аннан документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

4.7. Тикшерү барышында гражданинның Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта, аңа конкурста катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында ТР ДТИ җитәкчесе тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.8. Конкурста катнашуга кертелмәгән, вакант вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучы бу карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.9. ТР ДТИ граждан хезмәтенең бер вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидатның булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яисә вазыйфага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә конкурсның узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.10. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач ТР ДТИ җитәкчесе конкурсның икенче этабын уздыру датасы (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көне узганчы), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, ТР ДТИ җитәкчесе конкурсның икенче этабын уздыру чорын билгели.

ТР ДТИ кадрлар бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көне узганчы, ТР ДТИ һәм Федераль мәгълүмат системасы рәсми сайтларында аны уздыруның датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләмәләрне җибәрә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, – Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында.

4.11. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

«Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы»

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Кадрларның бердәм мәгълүмат системасы) кандидатлар турында мәгълүмат кертелә;

конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары бәяләнә;

ТР ДТИ граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе тарафыннан карары кабул ителә;

Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында конкурс нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

Федераль мәгълүмат системасы сайтында конкурс нәтиҗәләре бастырып чыгарыла.

4.12. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар тарафыннан тапшырылган белеме, граждан яисә башка төрле дәүләт хезмәтен узуы, башка төрле хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлар нигезендә, шулай ук тест уздыруны, шәхси әңгәмә уздыруны, язмача эшне (эссе), документ проектын әзерләүне үз эченә алырга мөмкин булган бәяләү методларын кулланып, конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә һөнәри дәрәҗәсен бәяли. Конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә карап, төрле методлар кулланылырга мөмкин. Бу вакытта кандидат белән тест һәм шәхси әңгәмә уздыру барлык кандидатлар өчен дә мәҗбүри методлар булып тора.

4.12.1. Язма эш (эссе) өчен (алга таба – Эш) граждан хезмәтенең конкурс уздырыла торган вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме) буенча вазыйфаи бурычлардан, шулай ук аталган вазыйфаларны биләү өчен квалификация таләпләреннән чыгып төзелгән сораулар (биремнәр) кулланыла.

Конкурс комиссиясенә кимендә 10 календарь көне кала кандидатларга Эш сораулары (биремнәре) җибәрелә, ул конкурс уздырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе яисә кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре тарафыннан билгеләнә һәм конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан килештерелә.

Эш түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

язма эшнең күләме – 2дән 4 биткә кадәр (титул битеннән һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән тыш);

шрифты – Times New Roman, зурлыгы 14, берле интервал аша.

Эштә кулланылган чыганакларга сылматалар булырга тиеш.

Эш кандидатлар тарафыннан конкурс комиссиясе сәркатибенә конкурс комиссиясе утырышын уздырырга кимендә 8 календарь көне калганчы тапшырыла.

Эшне бәяләү нәтиҗәләре ТР ДТИ Эш темасын билгеләгән структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан кыска белешмә рәвешендә рәсмиләштерелә, анда актыккы балл күрсәтелә, ул түбәндәге критерияләр буенча чыгарыла:

| т/с | Критерияләр | Бәя |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Рәсмиләштерүнең билгеләнгән таләпләренә туры килә | 0 башлап – 1, бирелә<br>0 – туры килми<br>1 – туры килә |
| 2 | Теманың ачылышы | 0 башлап – 1, бирелә<br>0 – ачылмаган<br>1 – ачылган |
| 3 | Аналитик сәләтләре, мантыйкый фикерләве | 0 башлап – 1, бирелә<br>0 – түбән дәрәҗәдә<br>1 – җитәрлек дәрәҗәдә |
| 4 | Бирелгән тема буенча тапшырылган тәкъдимнәрнең нигезләнгән булуы һәм гамәлдә башкарып булучанлыгы | 0 башлап – 5, бирелә<br>0 – башкарып булмый,<br>5 – хәзерге шартларда гамәлдә башкаруның югары дәрәҗәсе |
| 5 | хокукый һәм лингвистик грамоталылыгы | 0 башлап – 2, бирелә<br>0 – түбән дәрәҗәдә<br>1 – рөхсәт ителә торган дәрәҗәдә<br>2 – югары дәрәҗәдә |

Эшне бәяләгәндә максималь балл – 10 балл, минималь балл – 5 балл.

Объектив бәяләүне уздыру максатларында кандидатлар тарафыннан әзерләнгән Эшләрнең аноним булуы тәэмин ителә.

4.12.2. Кандидат тарафыннан документ проектын әзерләү аның вазыйфаи регламентта билгеләнгән һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле вазыйфаи бурычларның турыдан-туры үтәлүе өчен кирәкле белемнәрен һәм күнекмәләрен гамәлдә бәяләү мөмкинлеген бирә.

Конкурс комиссиясе утырышына кадәр кимендә 10 календарь көне кала кандидатларга гражданин мөрәҗәгатенә җавап проектын, норматив хокукый акт проектын (теркәлә торган аңлатма язуы белән бергә) яки әзерләнеше граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) вазыйфаи бурычлары исәбенә керә торган башка төрле документны әзерләргә тәкъдим ителә. Әлеге максатларда кандидатларга эш башкару буенча күрсәтмәләр һәм документ проектын тиешле рәвештә әзерләү өчен кирәкле бүтән документлар бирелә.

Эш кандидатлар тарафыннан конкурс комиссиясе сәркатибенә конкурс комиссиясе утырышын уздырырга кимендә 8 календарь көне калганчы тапшырыла.

Биремне билгеләү һәм әзерләнгән документ проектын бәяләү граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс уздырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан яисә кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан

уздырылырга мөмкин. Бу вакытта объектив бәяләү уздыру максатларында әзерләнгән документ проектының аноним булуы тәэмин ителә.

Документ проектын бәяләү нәтиҗәләре кыска белешмә рәвешендә рәсмиләштерелә, анда актыккы балл күрсәтелә, ул түбәндәге криетрияләр буенча чыгарыла:

| т/с | Критерияләр | Бәя |
|---|---|---|
| 1 | Рәсмиләштерүнең билгеләнгән таләпләренә туры килә | 0 башлап – 1, биредә<br>0 – туры килми<br>1 – туры килә |
| 2 | мәсьәләнең асылын аңлау, кандидатның документ проектын эшләү өчен нигез булып хезмәт иткән төп фактларны һәм проблемаларны ачыклавы | 0 башлап – 1, биредә<br>0 – аңламаган,<br>1 – аңлаган |
| 3 | Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы нормаларын дөрес куллануны исәпкә алып, документ проектын эшләү өчен нигез булып хезмәт иткән проблемаларны хәл итү юлларын чагылдыруы | 0 башлап – 5, биредә<br>0 – чишелешләр тәкъдим ителмәгән,<br>5 – проблемаларны хәл итүнең иң рациональ юлы тәкъдим ителгән |
| 4 | Аналитик сәләтләре, мантыйкый фикерләве | 0 башлап – 1, биредә<br>0 – түбән дәрәҗәдә<br>1 – җитәрлек дәрәҗәдә |
| 5 | хокукый һәм лингвистик грамоталылыгы | 0 башлап – 2, биредә<br>0 – түбән дәрәҗәдә<br>1 – рөхсәт ителә торган дәрәҗәдә<br>2 – югары дәрәҗәдә |

Документ проектын бәяләгәндә максималь балл – 10 балл, минималь балл – 5 балл.

4.12.3. Тест уздыру юлы белән кандидатларның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм ТР ДТИ кадрлар резервына кертү өчен Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләре, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе турындагы законнар турында белемнәр, мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендәге белемнәр һәм күнекмәләр дәрәҗәсен, шулай ук профессиональ хезмәт эшчәнлегенең өлкәсенә һәм төренә карап, белемнәрен һәм күнекмәләрен бәяләү гамәлгә ашырыла.

Тест уздыруны оештыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан ТР ДТИ Кадрларның бердәм мәгълүмат системасына килгән заявкалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тест уздыру өчен заявка Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында конкурс комиссиясе утырышына кадәр кимендә ике атна калгач формалаштырыла.

Тест уздыру Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар өчен тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган Тест уздыру методикасына туры китереп гамәлгә ашырыла.

Тест уздыру нәтиҗәләре Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында чагылдырыла. Конкурс комиссиясе сәркатибе нәтиҗәләрне аларны 10 баллы системага күчерү юлы белән кыска белешмә рәвешендә рәсмиләштерә.

Тест уздыру нәтиҗәләрен бәяләгәндә максималь балл – 10 балл, минималь балл – 5 балл.

4.12.4. Кандидатлар белән шәхси әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан уздырылырга тиеш.

Шәхси әңгәмә уздыру кысаларында кандидатның профессиональ дәрәҗәсен бәяләүгә юнәлдерелгән сораулар бирелә.

Әлеге максатларда, дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме) буенча вазыйфаи бурычларны исәпкә алып, граждан хезмәтенең һәр вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме) буенча сораулар исемлеге төзелә. Сораулар исемлеге комиссия утырышына ТР ДТИ кадрлар бүлеге тарафыннан граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс уздырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе белән яки кадрлар резервына керү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе белән берлектә әзерләнә.

Беренчел шәхси әңгәмә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс уздырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан яисә кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан уздырылырга мөмкин.

Конкурс комиссиясе утырышына кадәр уздырылган очракта, беренчел шәхси әңгәмә уздыру нәтиҗәләре турында конкурс комиссиясенә конкурс комиссиясе утырышы барышында телдән доклад формасында аны уздырган зат тарафыннан мәгълүмат җиткерелә.

Конкурс комиссиясе утырышы уздырылганда ТР ДТИ җитәкчесе карары нигезендә тиешле конкурс процедураларының үткәрелүе видеога һәм (яки) аудиога яздыру эше алып барыла.

Кандидат белән шәхси әңгәмә тәмамланганнан соң конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы кандидатны бәяләү нәтиҗәсен конкурс бюллетененә кертә, ул әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына туры китерелгән формада төзелә.

Әңгәмә уздыру нәтиҗәләрен бәяләгәндә максималь балл – 20 балл, минималь балл – 5 балл.

4.12.5. ТР ДТИ тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.

4.13. Кандидатның ахыргы баллы кандидатка конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан шәхси әңгәмә нәтиҗәләре буенча куелган балларның һәм кандидатның тест һәм башка төрле конкурс биремнәрен үтәү йомгаклары буенча җыелган балларның уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның ахыргы балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе секретаре аларның йомгаклау балларын киметү тәртибендә кандидатлар рейтингын төзи.

4.14. Конкурсның актыккы нәтиҗәсе булып әлеге Нигезләмәнең 2.11 пунктында күрсәтелгән карар бланкына яисә конкурс комиссиясе утырышының беркетмә бланкына кертелгән конкурс комиссиясе карары тора.

4.15. Әгәр конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе конкурста җиңүченең билгеләнмәве турында карар кабул итә.

4.16. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәте вакант вазыйфасына конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны ТР ДТИ кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге кандидат туплаган балларның гомуми суммасы максималь баллның кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш.

ТР ДТИ җитәкчесенең кандидатны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган шул ук төркемдә граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына кертү турында боерыгы кандидатның язмача формада рәсмиләштерелгән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасындагы ризалыгы булу шарты белән чыгарыла.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү ТР ДТИ җитәкчесе боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.17. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә җиткерелә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук срокта ТР ДТИ рәсми сайтында, Федераль мәгълүмат системасында һәм Кадрларның бердәм дәүләт системасында урнаштырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Конкурс бюллетене

«__» ________ 20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

______________________________________________________________________________
(аны биләү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфаның тулысынча аталышы,
______________________________________________________________________________
яки дәүләт органының кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркеменең аталышы)

Шәхси әңгәмә уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатка бирелгән балл

(Белешмә өчен: максималь балл ________ балл тәшкил итә)

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Балл | Куелган баллга кыскача дәлилләмә (зарурлык булганда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |

______________________________________________ ____________
(конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме*) (имзасы)

<*> Ата исеме булган очракта күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе
КАРАРЫ

___________________________________
(дәүләт органының аталышы)
«__» _______________________ 20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

1. Утырышта _____ конкурс комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.

| Конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Вазыйфа |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

2. Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылды

______________________________________________________________
(дәүләт органының структур бүлекчәсен күрсәтеп, вазыйфаның аталышы)
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________

3. Кандидатларны рейтинг буенча бәяләү нәтиҗәләре

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Актыккы балл | Рейтингтагы урыны (кими бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

4. Конкурста җиңүчене билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (барлык кандидатлар буенча тутырыла)

| (рейтингта беренче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «хупламыйм» | «тавыш бирмәдем» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| (рейтингта икенче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)* | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «хупламыйм» | «тавыш бирмәдем» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| (рейтингта өченче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)* | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «хупламыйм» | «тавыш бирмәдем» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә аңлатмалар (зарурлык булганда)
______________________________________________________________
______________________________________________________________

5. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе киләсе кандидатны конкурста җиңүче итеп таный

| Җиңүче дип танылган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы |
|---|---|
| | |

6. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге кандидатларны дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә киңәш итә

| Дәүләт органының кадрлар резервына кертү өчен киңәш ителгән кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфалар төркеме |
|---|---|
| | |

7. Конкурс комиссиясе утырышында түбәндәге комиссия әгъзалары катнашмады

_______________________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме)*

Конкурс комиссиясе рәисе ___________ ________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасарлары _________ ____________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Конкурс комиссиясе сәркатибе ____________ _________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Бәйсез экспертлар _________ ____________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*
_________ ____________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Иҗтимагый совет вәкилләре_________ ____________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Конкурс комиссиясенең
башка вәкилләре _________ ____________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*
_________ ____________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

<*> Ата исеме булган очракта күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы
БЕРКЕТМӘСЕ

____________________________________
(дәүләт органының аталышы)
«__» ________________________ 20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

1. Утырышта _____ конкурс комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.

| Конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Вазыйфа |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

2. Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең түбәндәге вазыйфалар төркеме буенча дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылды
______________________________________________________________________
(вазыйфалар төркеменең аталышы)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

3. Кандидатларны рейтинг буенча бәяләү нәтиҗәләре

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Актыккы балл | Рейтингтагы урыны (кими бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

4. Дәүләт органының кадрлар резервына кертү өчен кандидатны (кандидатларны) билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (бәяләү йомгаклары буенча максималь баллдан кимендә 50 процентын алган кандидатлар буенча тутырыла)

| ____________________________________________<br>(рейтингта беренче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)* | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «хупламыйм» | «тавыш бирмәдем» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| ____________________________________________<br>(рейтингта икенче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)* | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «хупламыйм» | «тавыш бирмәдем» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| ____________________________________________<br>(рейтингта өченче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)* | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «хупламыйм» | «тавыш бирмәдем» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә аңлатмалар (зарурлык булганда)
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________

5. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе дәүләт органының кадрлар резервына кертү өчен түбәндәге кандидатны (кандидатларны) билгели

| Җиңүче дип танылган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфалар төркеме |
|---|---|
| | |

6. Конкурс комиссиясе утырышында түбәндәге комиссия әгъзалары катнашмады

_______________________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме)*
_______________________________________________________________

Конкурс комиссиясе рәисе _____________ ___________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасарлары __________ ______________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Конкурс комиссиясе сәркатибе _____________ ___________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Бәйсез экспертлар ____________ ______________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

__________ ______________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Иҗтимагый совет вәкилләре__________ ______________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*
__________ ______________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

Конкурс комиссиясенең
башка вәкилләре __________ ______________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*
__________ ______________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)*

<*> Ата исеме булган очракта күрсәтелә.

Татарстан Республика Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесенә

______________________________
(инициаллар, фамилия)

______________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________
(яшәгән урыны буенча адресы;

______________________________
эш урыны, гариза тапшыру вакытына вазыйфасы)

______________________________
(кесә телефоны, эл. почтасы)

ГАРИЗА

Мине Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашырга кертүегезне сорыйм

______________________________________________________________
(вазыйфаның һәм бүлекчәнең аталышы)

______________________________________________________________

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә белән, шул исәптән вакант вазыйфага карата белдерелә торган квалификация таләпләре белән, таныштым. Персональ белешмәләрнең «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп эшкәртелүенә риза.

Конкурс уздыру датасы һәм урыны турында e-mail яки күрсәтелгән кесә

телефоны номерына СМС-хәбәр җибәрү ярдәмендә хәбәр алуга риза.

Гаризага түбәндәгеләрне терким:

____________________________________________________________

(теркәлә торган документларны санап чыгарга)

| | | |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |